КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 8 июнь г.Казань № 540

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләр советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибен раслау хакында» 2015 ел, 22 апрель, 275 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 15 февраль, 73 нче, 2016 ел, 7 ноябрь, 823 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1093 нче; 2018 ел, 22 сентябрь, 828 нче; 2019 ел, 12 апрель, 281 нче, 2019 ел, 29 июль, 629 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасының Муниципаль берәмлекләре советы һәм Татарстан

Республикасының муниципаль районнары (шәһәр округлары) арасында Татарстан Республикасы муниципаль районнарының (шәһәр округларының) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеге күрсәткечләренең планлаштырылган мәгънәләренә ирешү турында килешүләр төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Хисап чорыннан соң килә торган айның 10 көненә Күрсәткечләрнең факттагы мәгънәләре булмаган очракта, мондый Күрсәткечләр чираттагы хисап чоры йомгаклары буенча Күрсәткечләрнең үтәлеше турында мәгълүмат әзерләгәндә исәпкә алына.»;

3.3 пунктта «25» саннарын «20» саннарына алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин